**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы №67 19.10.2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 маендагы 95 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (08.10.2018 №111,27.11.2018 №118, 10.09.2020 №183 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 маендагы 95 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган ( 08.10.2018 №111, 27.11.2018 №118, 10.09.2020 №183 каралар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата хезмәт хакының күләмен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 маендагы 95 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи

затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән билгеләнгән, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәт вазыйфаларына туры китереп, 2022 елның 1 октябреннән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен башкарган муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә арттырырга (08.10.2018 №111, 27.11.2018 №118, 10.09.2020 №183) карарлар редакциясендә).

3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 маендагы 95 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган (08.10.2018 №111, 27.11.2018 №118, 10.09.2020 №183 карарлар редакцисендә), үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

а) 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлы күләме бермә-бер исәпләнә, ул 11 958,00 сум тәшкил итә.»;

4. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: С.З.Зиннурова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
АЛЬКЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1643003494
КПП 164301001